*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге "Балачак" балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*



# Чишмә башы

*Апрель, 2026 ел*




*Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар*













## Мин – Тукай якташы!

*И туган тел,и матур тел,*
*Синдә язлар кояшы.*
*Хозурланам ,туган телем –*
*Мин бит,Тукай якташы!*

*Татар телем – алтын йөзек,*
*Тукай йөзекнең кашы.*
*Күңелемдә шатлык ташый –*
*Мин бит Тукай якташы!*

*Беркайчан да сүнмәс кебек*
*Халкымның бу кояшы.*
*Горурланып әйтәм сезгә:*
*Мин бит Тукай якташы!*

*Гөлчирә Нәҗметдинова*





# «Кошлар - безнең дуслар»

3 апрель көнне Наласа балалар бакчасында "Кошлар - безнең дуслар" темасына күнелле чара оештырылды. Әлеге чараның максаты - балаларга кышлаучы һәм күчмә кошлар турында күбрәк мәгълүмат бирү,кошларга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. Экологиягә кагылышлы мондый чарага Татарстан Республикасының биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының " Ашыт" табигый тыюлыгы белгечләре Абрахманова Гөлнара Ильяс кызы,Шәйхетдинов Ильшат Шамил улы, Хурамшина Талия Тәлгать кызы чакырылды.

Ул чарага алдан ук әзерлек эшләре башланды.Берсеннән - берсе матур сыерчык ояларыннан күргәзмә оештырылды. Шушы темага карата стенд булдырылды. Тәрбиячеләр бу чараны бик күңелле һәм истә калырлык итеп оештырдылар. Балаларның барысы да актив катнашып , үзләренең белемнәрен күрсәттеләр.

Чара ахырында Шәйхетдинов Ильшат Шамил улы пультлы виртуаль чынбарлык күзлеге белән таныштырды. Балалар виртуаль чынбарлык күзлегеннән файдаланып,экология буенча яңа мәгълүмат үзләштерделәр, кызыксынулары артты. Хурамшина Талия Тәлгать кызы , Абрахманова Гөлнара Ильяс кызы үзләренең балаларга һәм балалар бакчасы коллективына матур, җылы теләкләрен җиткерделәр. Сыерчык оялары алып килгән балаларга грамоталар тапшырдылар һәм тәрбиячеләрнең хезмәте дә югары бәяләнде. Балалар бакчасы мөдире Гафурова Эльмира Рашат кызы килгән кунакларга олы рәхмәтен әйтте, эшләрендә уңышлар теләде. Шундый матур очрашулар киләчәктә дә насыйп булсын.












**«ЭКО ЯЗ 2026»**

***2026 елның 1 апреленнән санитар-экологик икеайлык кысаларында Татарстан Республикасында «ЭКО ЯЗ 2026» республика конкурсы башланып китте, безнең балалар бакчасы бу акциягэ бик теләп кушылды.***

***1 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ «Канатлы дусларга ярдәм ит!»***

*Кошлар көненә багышланган чаралар узды. Аларның максаты – мәктәпкәчә яшьтәге балаларның кошлар турындагы белемнәрен киңәйтү, табигатьтә аларның әһәмиятен аңлату, балаларда кошларны саклау һәм кайгырту теләген уятау. Балалар белән танып-белү экологик дәрес үткәрелде, аның барышында балалар кышлаучы һәм күчмә кошлар, аларның тышкы кыяфәтләре, кошларның табигатькә һәм кешегә китергән файдалары турында белделәр. Мәктәпкәчә яшьтәгеләр рәсемнәр, иллюстрацияләр карадылар, кошлар тавышлары язмаларын тыңладылар, дидактик һәм хәрәкәтле уеннар уйнадылар. Кошларга азык салгычлар урнаштырдылар.Алынган белемнәрне балалар рәсем ясау эшчәнлегендә ныгыттылар. Үткәрелгән эш нәтиҗәсендә балалар күп яңа һәм кызыклы нәрсәләр белделәр, мөһим кагыйдәне үзләштерделәр: "Кошларга рәнҗешергә кирәкми, кошларына ярдәм итәргә кирәк!"Шул уңайдан балалр әти -әниләре белән бик теләп сыерчык оялары ясап бакчабызга алып килделәр. Алар берсеннән берсе матур, бер берсенә ошамаган зәвыклы оялар булганар.*



***Килдегезме, дусларым,***
***Минем сыерчыкларым.***
***Оябызга куныгыз,***
***Балалар чыгарыгыз.***



***2 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ «Зоозабота»(хайваннар өчен приютларга ярдәм, йортсыз хайваннарны кайгырту турында яхшылык дәресләре)***

*ЭКОяз 2026: икенче атна — «Зоозабота» (хайваннар өчен приютларга ярдәм, йортсыз хайваннарны кайгырту турында яхшылык дәресләре) Татарстанда «ЭКОяз-2026» масштаблы экологик акция дәвам итә. Марафонның икенче атнасы хайваннар турында кайгыртуга багышланган һәм «Зоозабота»лозунгы астында уза. Тематик атнаның максаты-йортсыз хайваннар проблемасына игътибарны җәлеп итү , приютларга ярдәм итү, мәче һәм этләргә азык китерү.Безнең балалар бакчасында шулай ук йортсыз хайваннар өчен азык җыю буенча хәйрия акциясе дә узды.Балалар һәм аларның әти-әниләре,бакчабыз хезмәткәрләре бу акциядә актив катнаштылар.Без җыйган азыкны Татарстан Республикасы Балтач районының йортсыз хайваннар приютына җибәрәбез.Һәр балага һәм ата-анага акциядә катнашулары өчен рәхмәтебезне белдерәбез. Бу мәчеләр һәм этләр өчен һәр җыйган азык— ризык кына түгел, ә аларны онытмау билгесе дә.*



***3 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ « Икенчел чимал материалларын кулланып!»***

*3 нче атналыгы кысаларында безнең әти-әниләребез һәм без дә читтә калмадык. Балалар бакчасы өчен үз кулларыбыз белән матурлык тудырдык. Сатып алынган комплектлар урынына – фантазия, ә яңа материаллар урынына – гадәттә чүп чиләгенә эләккән әйберләр. Бүген безнең кулыбыздагы чүп-чар – ул иске төзелеш чиләкләре. Ротанг ярдәмендә бу чиләкләрдән матур чәчәк савытлары үрдек. Моны чәчәк кашпосы дип атыйлар. Ротангтан ясалган кашпо – җиңел, ныклы һәм оригиналь бизәк. Гадәти чәчәк савытыннан аермалы буларак, кашпо ешрак интерьер бизәге булып хезмәт итә. Ул чәчәк савытының ямьсез кыяфәтен яшерә, шулай ук яшел үсемлекләрне температура һәм дымлылыкның үзгәрешләреннән саклый, өй яки бакчада тәртипне, матурлыкны сакларга ярдәм итә. Әти-әниләребезгә,хезмәттәшләребезгә мондый файдалы осталык дәресе өчен зур рәхмәт! Балалар үзләре күреп экологның төп принцибын яхшы аңладылар: «Чүп-чар – ул яңа табыш!» Хәзер без иске әйберләргә яңа, матур тормыш бүләк итү мөмкинлеген тапкан белән өстәп бирдек.*

*Акциясе кысаларында безнең балалар, тәрбиячеләр белән бергә, бик тырышып, икенчел чималдан – пластик капкачлардан яңа уеннар ясадылбалалар бакчасының өлкән төркем балалары үз куллары белән кәгазь стаканнардан матур чәчәкләр ясадылар. Бу сихри чәчәкләрне эшчәнлек вакытында,өстәл, дидактик, үстерелешле уеннарда һәм өстәл театрында кулланырга була. Икенчел чималдан уенчыклар ясау, эшенең кызыклы булуы, балаларда игътибар үсешенә ярдәм итә, аның тотрыклылыгы арта, ирекле игътибар формалаша.*





***4 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ « Табигать язмышы — безнең кулларда!»***

*Эковеснаның яңа, дулкынландыргыч атнасына кушылыгыз! Татарстанда Экология иминлеге милли проектын яклау өчен үткәрелә торган «Эковесна-2026 » республика бәйгесенең 4 нче атнасы башланды. Бу атнаның төп максаты — туган җиребезне яшелрәк һәм сулышлырак итү. Без җимеш агачлары һәм куаклар утыртуга багышланган зур акциягә старт бирәбез!*

*Безнең бакчабызда тәрбияләнүче эко-волонтерлар да акциягә кушыла. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары әти-әниләре белән бергәләп, беренче агачларын утырталар, табигатьне сакларга өйрәнәләр.*
*«И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә - эш!»*












# «Тукайлы яз»

*Безнең балалар бакчасында ата- аналар һәм башлангыч сыйныф укытучысы Исмәгыйлова Мөнирә Мәсхут кызы өчен " Ачык ишекләр" көне булды.*

*Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары тәрбияче Алинә Фидаэль кызы сөйләм теле буенча эшчәнлек күрсәтте . Балалар барлык биремнәрне төгәл үтәп, матур итеп җавап бирделәр. Үзләренең белемнәрен күрсәттеләр.*

*Римма Нәзгать кызы нәниләр төркеме белән Бөек шагыйребез Г.Тукайга багышланган «Бәйрәм бүген!» кичәсен башлап җибәрде. Зурлар төркеме белән Рафия Ансар кызы «Шүрәле һәм аның дуслары» әкиятен сәхнәләштереп күрсәттеләр.*

*Ата аналар һәм Мөнирә Мәсхүт кызы бакча коллективы хезмәткәрләренә карата матур теләкләрен җиткерделәр, көнебез күңелле һәм шатлыклы хисләр белән тулды.*












***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Гафурова Р.А.,Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары***: *Хөсәенова Р.Н., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР, Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*